| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.11.2022 Буа шәһәре № 379/Бк/к

«Хәрби хезмәткәрләр гаиләләрендәге Буа муниципаль районы мәгариф оешмаларында укучы һәм тәрбияләнүчеләргә ташламалар бирү турында» Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 6 октябрендәге 301/Бк-к номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы (24.09.2022ел редакциясендә), «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» (30.12.2021ел редакциясендә) Федераль законнар нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарына ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Хәрби хезмәткәрләр гаиләләрендәге Буа муниципаль районы мәгариф оешмаларында укучы һәм тәрбияләнүчеләргә ташламалар бирү турында» Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 6 октябрендәге 301/Бк-к номерлы карарына (алга таба - Карар), үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар арасыннан Татарстан Республикасында төзелгән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләргә һәм затларга, «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарга мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкаланган, шулай ук ата-аналары махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге балалары булган гаиләләргә (гаилә әгъзаларына) социаль ярдәмнең түбәндәге өстәмә чараларын билгеләргә:

1.1. Төп һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучыларын тукландыру буенча ата-аналар түләвеннән азат итәргә;

1.2. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында 1-7 яшьлек балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен гражданнарны ата-аналар түләвеннән азат итәргә;

1.3. Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмасына чираттан тыш кабул итү хокукын бирергә.».

2. Әлеге карар имзаланган көннән законлы көченә керә һәм http//buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш һәм 2022 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л. Н. Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов